Уг. kw 27
A. T. S. S. Ç. Qazan LENIN isem.
ӨLKӘ MASSA KITAPXANӘSE TEP KITAP SAQLAY BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань

ҖОМГА
16 МАРТ
1940 ел
№ 63 (5863)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

РӘХМӘТ БЕЛДЕРҮ

Минем илле еллыгым уңае белән котлау һәм тәбрик җибәргән барлык оешмаларга, группаларга һәм кешеләргә чын күңелдән рәхмәт белдерәм.

В. МОЛОТОВ.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕН ЧАКЫРУ ТУРЫНДА

Шушы елның 29 нчы мартында Москва шәһәрендә Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советының Алтынчы Сессиясен чакырырга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
14 март, 1940 ел.

ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕҢ БОЛЬШЕВИСТИК СТИЛЕН ҮЗЛӘШТЕРЕРГӘ

ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе үзенең эшен тәмамлады. Конференция идея-политик яктан гаят югары дәрәҗәдә үтте. Делегатлар ВКП(б) Өлкә Комитетының эшен һәр яктан җентекләп тикшерделәр, үтелгән юлга большевистик йомгак ясадылар һәм көндәлек эштә яшәп килә торган җитешсезлекләрне кыю рәвештә ачып салдылар. Республикабызда партияле кадрларның идея ягыннан һәм практик эш ягыннан тагын да үскәнлекләре бу конференциядә бөтен тулылыгы белән чагылды.

Конференция, ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды карарларын үтәүнең барышын тикшерү билгесе астында үтте. ВКП(б) Өлкә Комитетының отчетында һәм делегатларның чыгышларында күренгәнчә, партиянең Татарстан оешмасы XVIII нче съезд карарларын тормышка ашыру буенча зур гына эшләр башкарды. Партия оешмасы сан ягыннан үсте, сыйфат ягыннан яхшырды, тагын да сугышчанрак һәм сәләтлерәк булып әверелде. Хуҗалык бурычларын үтәү буенча да алга таба зур адым ясалды. Шуның белән бергә, партоешмаларның, хуҗалык органнарының эшләрендә күп кенә һәм җидди җитешсезлекләр дә дәвам итеп килә әле. Конференциядә бу җитешсезлекләр ачык итеп күрсәтелделәр һәм аларны бетерү юллары билгеләнде.

Партиянең кайбер оешмаларының һәм хуҗалык органнарының практик эшләрендә төп җитешсезлек шуннан гыйбарәт ки, алар әле җитәкчелекнең большевистик стилен үзләштереп җиткермәгәннәр. Безнең күп кенә җитәкчеләребез еш кына хәлләрдә агымдагы эшләргә күмелеп, төп мәсьәләне читләтеп үтәләр, үтәлүне тикшерү эшләре, кадрлар сайлап алу, аларны дөрес урнаштыру һәм өйрәтү эшләре бер читтә калып килә. Хуҗалыкның аерым тармакларындагы эшләргә тирән анализ ясалып барылмау нәтиҗәсендә, зур гына җитешсезлекләр һәм ялгышлар кабатлана. Мондый зарарлы практика Татарстан Совнаркомында, Татнаркомземда, Коммуналь Хуҗалык Халык Комиссариатында, Наркомместпромда һәм Казан тимер юлы идарәсендә аеруча киң урын алган.

Мисаль өчен Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариатын алып карыйк. Бу наркомат республикадагы барлык җир органнарын һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендәге башка хуҗалык оешмаларын берләштерә. Шулай булгач Татнаркомзем бу оешмаларга үзе үрнәк күрсәтергә, аларга җитәкчелекнең Сталинчыл принципларын өйрәтергә тиеш иде. Ләкин, кызганычка каршы, Татнаркомзем җитәкчеләренең эшендә мондый большевистик стильне күреп булмый әле. Алар күп кенә хәлләрдә булып үткән фактларны теркәп утырудан, приказлар, циркулярлар язудан бушамыйлар. Ә бу приказлар, партия һәм хөкүмәт карарлары урыннарда ничек үтәлә, җир органнары бу карарларны үтәү өчен ничек көрәшәләр һәм аларга нинди булышлык кирәк? Татнаркомзем җитәкчеләрен бу мәсьәләләр аз гына да кызыксындырмый. Алар урыннарда сирәк булалар һәм колхозларда, совхозларда бара торган эшне начар беләләр.

Татнаркомместпром җитәкчеләренә карата да шуны ук әйтергә кирәк. Бу наркоматка караган предприятиеләрнең бер өлеше (Татполиграф, гармон фабрикасы һ. б.) гафу ителмәслек начар эшли. Наркомат җитәкчеләренең төп бурычлары—планны үтәүдә артта баручы предприятиеләрне өзеклектән чыгарудан, аларга конкрет булышлык оештырудан гыйбарәт булырга тиеш иде. Фактта исә моның киресен күрергә туры килә. Наркомместпром җитәкчеләре еш кына хәлләрдә гомуми саннар артына яшренеп, чынбарлыкны күрми үтәргә яраталар. Предприятиенең үзенә барып хуҗалык җитәкчесенең кимчелекләрен күрсәтү, аларны бетерүдә ярдәм итү һәм шул юл белән кадрларны өйрәнү практикасы кулланылмый.

Күп кенә наркоматларның һәм хуҗалык оешмаларының көндәлек эшләрендә кабатланып килә торган мондый практиканы большевистик практика дип буламы? Билгеле, юк. Җитәкчелекнең большевистик стиле мондый канцеляриячә практика белән һич тә килешә лмый. Җитәкчелекнең большевистик стиле ул—Сталинчыл стиль. Иптәш Сталин безне болай дип өйрәтә:

„Дөрес җитәкчелек итү нәрсә дигән сүз?

Ул һич тә канцеляриядә утыру һәм директивалар язып тору дигән сүз түгел.

Дөрес җитәкчелек итү—ул болай дигән сүз:

беренчедән, мәсьәләне дөрес хәл итүне табу, ә дөрес хәл итүне, безнең җитәкчелекнең нәтиҗәләрен үз җилкәләрендә сынаучы массаның тәҗрибәсен исәпкә алмый торып табу мөмкин түгел;

икенчедән, дөрес карарны үтәүне оештыру, ләкин моны, массаның турыдан-туры ярдәменнән башка эшләү мөмкин түгел;

өченчедән, бу карарның үтәлешен оештыру, моны да шулай ук, массаның турыдан-туры ярдәменнән башка эшләү мөмкин түгел".

Безнең партияле һәм партиясез җитәкчеләребез үзләренең эшләрен менә шушы күрсәтмәләр нигезендә оештырырга, масса белән ныклы элемтәдә булырга тиешләр. Дөрес карарлар чыгару гына җитмәгәнлекне, бәлки аларның үтәлешләрен системалы рәвештә тикшереп торырга кирәклекне бик нык истә тотарга һәм бөтен эшне шул нигездә алып барырга кирәк.

Кызганычка каршы, безнең күп кенә җитәкчеләребездә нак менә шушы сыйфат—үтәлүне тикшерү эшләре җитешми. Бу кимчелек ВКП(б) Өлкә Комитетының үзендә дә һәм Татсовнаркомда да шактый урын алып тора. ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Татарстан Совнаркомы тарафыннан чыгарылган карарларның бер өлеше үтәлмичә калуын бары тик шуның белән генә аңлатырга мөмкин. Партиянең XXI нче өлкә конференциясе ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Татсовнаркомның, шулай ук башка наркоматларның эшләрендә кабатланып килә торган мондый яраксыз практиканы каты рәвештә гаепләде һәм аларны бик тизлек белән бетерүне таләп итте. Партия, профсоюз оешмалары һәм хуҗалык органнары җитәкчеләре конференциянең бу күрсәтмәләреннән үзләре өчен конкрет нәтиҗә ясарга тиешләр.

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе республикабыз өчен гаят әһәмиятле карарлар кабул итте. Бу карарлар партиябезнең XVIII нче съезды директиваларын һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин күрсәтмәләрен тулы һәм төгәл үтәүгә юнәлдерелгәннәр. Партия оешмалары киң масса арасында конференция материалларын, анда сөйләнгән речьләрне ныклап өйрәнүне оештырырга, бу эшкә барлык агитаторлар кадрларын тупларга һәм шул нигездә политик-масса эшләренең тагын да көчәюенә ирешергә тиешләр.

Иптәш Сталинга

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Партиянең Татарстан оешмасының XXI нче Өлкә Конференциясе Сезгә, — Маркс — Энгельс — Ленин эшен даһи дәвам иттерүчегә, партиянең һәм халыкларның зирәк һәм сөекле юлбашчысына, марксизм-ленинизмның бөек теоретигына, социализмның җиңүләрен оештыручыга һәм рухландыручыга үзенең ялкынлы большевистик сәламен җибәрә!

Партиябезнең XVIII нче съездының тарихи карарларын уңышлы үтәү нигезендә социализмның илебездә ирешелгән гаят зур җиңүләре барлык хезмәт ияләрендә бөек шатлык хисе һәм мораль канәгатьләнү тудыралар.

Орденлы Татарстанның большевиклары, бөтен партия белән берлектә, узган чор эчендә яңа уңышларга ирештеләр. Безнең партия оешмабызга шәһәрләрнең һәм авылларның меңнәрчә иң яхшы алдынгы һәм атаклы кешеләре керделәр, аның массалар белән элемтәсе тагын да ныграк булып әверелде, хезмәт ияләре арасында партиянең политик авторитеты тагын да үсте. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларда коммунистлар һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының гүзәл җиңүе моның ачык дәлиле. Бу барлык уңышлар өчен без ВКП(б) Үзәк Комитетына һәм иптәш Сталин, Сезгә, безнең турыда даими рәвештә кайгыртучанлык һәм игътибар хисе күрсәтүегез өчен бурычлыбыз.

Партиянең Татарстан оешмасының XXI нче Өлкә Конференциясе ВКП(б) ның XVIII нче съездының тарихи карарларының үтәлешен тикшерү билгесе астында үтте. ... ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын тормышка ашыру өчен көрәшнең алдагы юлларын билгеләде. Партиянең Татарстан оешмасы XXI нче конференциясенә тагын да ныгыган хәлдә, ВКП(б) Үзәк Комитеты тирәсендә тагын да тыгызрак тупланган хәлдә һәм Сезнең җитәкчелегегездә алга, яңа җиңүләргә баруда большевистик омтылыш белән рухланган хәлдә килде.

Кадерле Иосиф Виссарионович! Без, өченче бишьеллыкның бурычлары гаять зур һәм катлаулы икәнлеген беләбез, һәм Татарстан большевиклары барлык көчләрне бу мактаулы бурычларны үтәүгә бирәчәкләр, барлык предприятиеләрдә, колхозларда һәм совхозларда стахановча эшләү өчен үзләренең көчләрен кызганмыйча көрәшерләр, социалистик төзелешнең барлык участокларында яңа уңышларга ирешерләр дип Сезне ышандырабыз.

Хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә Сезнең тарафыгыздан куелган бурычлар зур һәм мактаулы. Без, барлык фәннәрнең фәнен — марксизм-ленинизм теориясен өйрәнү турында, барлык кадрларыбызны, һәм беренче чиратта, партия кадрларын һәм совет интеллигенциясен идея ягыннан коралландыру һәм политик яктан чыныктыру турында Сезнең күрсәтмәләрегезне большевикча үтәргә вәгъдә бирәбез.

Сталинчыл зирәк тынычлык политикасын чын күңелдән хуплаган хәлдә, без киләчәктә дә безнең социалистик Ватаныбызның оборонасын тагын да ныгытырбыз. Татарстан АССР ның хезмәт ияләре бөтен совет халкы кебек үк, партиянең һәм хөкүмәтнең беренче чакыруы белән, бөтен данлыклы Кызыл Армия белән берлектә, Сезнең исмегез белән, үзләренең туган совет җирен күкрәкләре белән сакларга басарга һәр минут хәзер торалар.

Иптәш Сталин, Сезнең партиябез бөтен партия белән берлектә, бөтен совет халкы белән берлектә, ВКП(б) Үзәк Комитеты җитәкчелегендә, иптәш Сталин, Сезнең җитәкчелегегездә алга, коммунизмга таба барабыз.

Яшәсен Ленин—Сталинның данлыклы Коммунистик Партиясе!

Яшәсен Ленинче — Сталинчы Үзәк Комитет!

Яшәсен юлбашчыбыз, остазыбыз һәм дустыбыз бөек Сталин!

Иптәш Ворошиловка

Кадерле Климент Ефремович!

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче Өлкә Конференциясе Сезгә, иптәш Сталинның иң якын дустына һәм турылыклы көрәштәшенә, безнең данлыклы Кызыл Армиябезнең сөекле полководецына, Советлар Союзының беренче маршалына үзенең ялкынлы, большевистик сәламен җибәрә!

Бөек Сталин белән берлектә һәм аның җитәкчелегендә Сез эшче һәм крестьяннар армиясен төзедегез, һәм аны куәтле һәм җиңелмәслек итеп чыныктырдыгыз. Илебезнең дошманнарына каршы бөек көрәш елларында Кызыл Армия үзен бетмәс дан белән каплады. Сталинчыл бишьеллыклар Кызыл Армиябезнең сугышчан куәтен тагын да ныгытты, аны дөньяда иң алдынгы армиягә әйләндерделәр. Безнең армиябез үзенең какшамаслык көчен һәм Ватаныбызга чын күңелдән бирелгәнлеген Хасан күле янындагы, Халхин-Гол ярларындагы, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия кырларындагы сугышларда, ак финнәргә каршы сугышларда күрсәтте.

Орденлы Татарстанның хезмәт ияләре бөтен совет халкы кебек үк, Ленинград Хәрби Округының героик частьләренең җиңүле рәвештә алга баруларын гаять зур горурлык һәм мәхәббәт белән күзәтеп тордылар. Карелия бугазының ныгытмалары Кызыл Армиянең дәһшәтле көче алдында тора алмадылар. Англия—Франциянең сугыш уты кабызучылары тарафыннан какшамаслык дип белдерелгән ак финнәрнең ныгытмалары тар-мар ителде.

183 миллион халыкның ышанычы белән, бөек Сталин исме белән рухланган Кызыл Армиянең һәм Кызыл Флотның сугышчылары, командирлары һәм политработниклары большевиклар ала алмаслык крепостьның юклыгын бөтен дөньяга күрсәттеләр.

СССР белән Финляндия республикасы арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрне без гаять зур канәгатьләнү белән кабул алдык. Бу данлыклы вакыйга Сталинчыл тынычлык политикасының яңа җиңүе булды. Совет халкы үз теләгенә иреште. Бүгеннән башлап СССР ның төньяк-көнбатыш чикләрендә тынычлык урнаштырылды, социалистик революциянең бишеге булган Ленин шәһәренең куркынычсызлыгы тәэмин ителде.

Совет халкы үз хөкүмәтенең зирәк политикасын чын күңелдән яклый дип тапкан хәлдә, Ватаныбызның куәтен, аның оборона сәләтен тагын да зуррак энергия белән ныгытыр.

Кадерле Климент Ефремович, Сезне ышандырабыз, Татарстан большевиклары оборона эшенең тагын да киңрәк җәелүен тәэмин итәрләр, хезмәт ияләренең мобилизацион хәзерлеген тагын да югарырак күтәрерләр һәм һәрбер фабриканы, заводны һәм колхозны оборонаның җиңелмәслек крепостена әйләндерделәр. Без партиянең һәм хөкүмәтнең беренче чакыруы белән Кызыл Армиянең сугышчан дан белән капланган байрагы астына басарга һәм революция казанышларын күкрәгебез белән сакларга һәр вакыт хәзер торабыз.

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының героик сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына хөрмәт һәм дан!

Иптәш Ворошилов, Сезгә, сыналган пролетар полководецка, дөньяда бердән-бер социалистик дәүләтнең коралы көчләре җитәкчесенә хөрмәт һәм дан!

Яшәсен безнең җиңүләребезне оештыручы дустыбыз, юлбашчыбыз һәм остазыбыз бөек Сталин!

ХРОНИКА

ССР Союзы Совнаркомы **Д. М. Бубнов, И. Ф. Масленников, В. А. Махнев, З. А. Мосесов, А. Н. Столяров, Г. Я. Удрас, М. К. Черняк, В. Г. Жуков, А. Д. Исанов** һәм **И. М. Карташов** иптәшләрне СССР Совнаркомы янындагы Совет Контроле Комиссиясенең члennары итеп раслады.

(ТАСС).

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче Өлкә Конференциясе үзенең эшен тәмам итте

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ПЛЕНУМЫ

15 нче мартта ВКП(б) ның яңа сайланган Өлкә Комитетының пленумы булды.

Пленум ВКП(б) Өлкә Комитетының беренче секретаре итеп иптәш **А. М. Алемасовны**, икенче секретаре итеп иптәш **Е. Я. Матвеевны**, өченче секретаре итеп иптәш **З. З. Абдельмановны**, кадрлар буенча секретарь итеп иптәш **А. У. Долотказинны**, пропаганда буенча секретарь итеп иптәш **С. А. Мөхәметовны** бер тавыштан сайлады.

А. М. Алемасов, Е. Я. Матвеев, З. З. Абдельманов, А. У. Долотказин, С. А. Мөхәметов, Г. А. Динмөхәметов, С. Х. Гафиятуллин, Е. М. Морозов, И. Г. Бычков иптәшләрдән 9 кеше составында бюро сайланды.

А. П. Перов, С. М. Шәрәфиев һәм **Н. Н. Киселев** иптәшләр бюро членлыгына кандидатлар итеп сайландылар.

Аннары пленум ВКП(б) Өлкә Комитеты бүлекләренең мөдирләрен раслады: оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире итеп иптәш **К. П. Жуков**, авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире итеп иптәш **А. М. Саланов**, хәрби бүлек мөдире итеп иптәш **В. К. Львов**, оборона промышленносте бүлеге мөдире итеп иптәш **А. Ф. Абецедарский**, җиңел һәм азык промышленносте бүлеге мөдире итеп иптәш **А. Г. Хәкимов**, транспорт бүлеге мөдире итеп иптәш **М. М. Гайнеттинов** расланды. Кадрлар бүлеге мөдире урынбасары итеп иптәш **А. Ф. Постнова**, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары итеп иптәш **Ю. З. Закиров** расланды.

„Красная Татария" газетасы редакторы итеп иптәш **А. И. Анушкин**, „Кызыл Татарстан" газетасы редакторы итеп иптәш **Һ. А. Абдрахманов** һәм „Херле Ялав" газетасы редакторы итеп иптәш **И. В. Скворцов** расланды.

КОНФЕРЕНЦИЯ КӨНДӘЛЕГЕ

Кичә, 15 нче мартта, ВКП(б) ның XXI нче Өлкә Конференциясенең иртәнге утырышында ВКП(б) Өлкә Комитетының пленумы составына членлыкка, кандидатлыкка һәм ревизия Комиссиясенә членлыкка кандидатуралар күрсәтү, тикшерү һәм сайлаулар булды.

Конференциянең кичке утырышында санау комиссиясе председателе иптәш Хәмидуллин, ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы составына, яшрен (ябык) тавыш бирү тәртибендә, член итеп 65 кеше, кандидат итеп 23 кеше, ревкомиссия составына член итеп 15 кеше сайланганлыкны белдерде.

Аннары, делегатлар гаять зур күтәренкелек белән бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга хат кабул иттеләр.

Шулай ук, конференция бөек полководец, Советлар Союзының беренче маршалы иптәш Ворошиловка хат кабул итте. Залда:

— Яшәсен бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин!

— Яшәсен җиңелмәслек Кызыл Армия!

— Яшәсен бөек полководец иптәш Ворошилов! дигән тавышлар һәм көчле алкышлар яңгырады. Конференцияне ябу алдыннан, иптәш Алемасов болай диде:

— ВКП(б) ның XXI нче Өлкә Конференциясе алдында торган бурычлар тулысынча үтәлде. Барлык мәсьәләләр буенча да карарлар кабул ителде. Хәзер бурыч—урыннарга кайту белән, ВКП(б) ның XXI нче Өлкә Конференциясенең, район конференцияләренең һәм башлангыч партоешмаларда булып үткән отчет-сайлау җыелышларының карарларын үтәүгә партиялеләр һәм партиясезләр массасын туплаудан һәм шуның белән партиянең XVIII нче съезды куйган бөек бурычларны үтәү өчен большевистик көрәшне тәэмин итүдән гыйбарәт.

Шуннан соң иптәш Алемасов ВКП(б) ның XXI нче Өлкә Конференциясен ябык дип игълан итте.

ПАРТИЯНЕҢ ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI НЧЕ ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ТАРАФЫННАН ВКП(б) НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ПЛЕНУМЫ ЧЛЕННАРЫ ИТЕП ТҮБӘНДӘГЕ ИПТӘШЛӘР САЙЛАНДЫЛАР

Абдрахманов Һ. А.	Гильдеев Я. Н.	Михайлин Н. П.
Абдельманов З. З.	Гринько И. К.	Морозов Е. М.
Алемасов А. М.	Гришин В. М.	Мөхәметов С. А.
Ананьев Ф. Г.	Гобәйдуллин Х. Ф.	Мурин Г. И.
Анушкин А. И.	Динмөхәметов Г. А.	Нацибуллин Я.
Әхмәдуллин Г. А.	Долотказин А. У.	Перов А. П.
Әхметшина Р. С.	Жуков К. П.	Новиков М. М.
Әхтямов Щ. А.	Забродченко А. А.	Петров А. А.
Әюпова А. К.	Измайлова Г. Г.	Постнова А. Ф.
Бәдерттинев Х. В.	Ильин И. М.	Саланов А. М.
Баһаветтинов Б. Б.	Киселев Н. Н.	Сәмигуллин Г. С.
Барышников А. Г.	Контюков У. Т.	Сахабеттинов Г. С.
Блюминцев М. А.	Кәримев З. З.	Суганов Н. А.
Быстров В. Е.	Ковальский Ф. М.	Тихонов Г. П.
Бычков И. Г.	Колесникова А. И.	Хәкимҗанов С. Х.
Вәлиев С. Х.	Ковалева А. В.	Хасанов Л. Л.
Вахрушев Г. С.	Латыйпов Н. Х.	Шәрәфиев С. М.
Вәлиуллин Х. В.	Львов В. К.	Шигаев Е. И.
Воробьев К. А.	Матвеев Е. Я.	Школдов П. И.
Гапонова О. И.	Марков А. Н.	Шульгин В. В.
Гафиятуллин С. Х.	Максимов Н. С.	Шакуров А. Ш.
Гаязеттинов А. Г.	Михайлов А. И.	

ПАРТИЯНЕҢ ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI НЧЕ ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ТАРАФЫННАН ВКП(б) НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ПЛЕНУМЫ ЧЛЕНЛЫГЫНА КАНДИДАТЛАР ИТЕП ТҮБӘНДӘГЕ ИПТӘШЛӘР САЙЛАНДЫЛАР

Абецедарский А. Ф.	Закиров Ю. З.	Осинцев Н. А.
Басыйров Ш. Б.	Кияев И. Л.	Прокофьев С. Е.
Васильев П. К.	Кутлин Х. А.	Семенов Н. С.
Валиди С. Б.	Латыйпов Н. Х.	Скворцов И. В.
Григорьев Е. Ф.	Мельников А. М.	Фардеев А. Ф.
Демидов М. Д.	Назаров А. П.	Хәкимов А. Г.
Дрягин К. А.	Никитин И. К.	Шәмсеттинов Г. Х.
Захаров П. И.	Огольцов М. Я.	

ПАРТИЯНЕҢ ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI НЧЕ ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ТАРАФЫННАН ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫНА ТҮБӘНДӘГЕ ИПТӘШЛӘР САЙЛАНДЫЛАР

Арнаутов А. Д.	Гайнеттинова М. Ф.	Плакатин А. П.
Афанасьева Е. Ф.	Гафиятуллин Х. Г.	Плечков А. В.
	Глухов Н. И.	
Әхметов И. З.	Куренков А. Д.	Тенчурин З. В.
Әхмәдуллин Г. Л.	Макарьев П. П.	Уткин Р. В.
Бусарев И. С.	Никишкин П. И.	Федоров В. Ф

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ҺӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Үтәлешне тикшерү—мөһим бурыч

ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Долотказин речённән

Иптәшләр! Мин, промышленность мәсьәләләренә, бигрәк тә район промышленностена тукталырга телим. Промышленность өлкәсендә ирешелгән уңышлар аз түгел, алар турында иптәш Әлемасов әйтте инде. Бу уңышлар безнең район һәм башлангыч партоешмаларның производство мәсьәләләре белән яхшырак шөгылләнә башлауларын, партия-политик эшне хуҗалык эшләренә бәйләп алып бара башлауларын күрсәтәләр.

Тимер юл транспорты турында берничә сүз. Өлкә Комитеты тимер юл транспортының торышы, аның аерым бүлекләре турында күп кенә тикшерүләр оештырды һәм эшне яхшырту өчен конкрет чаралар күрде. Без дүрт айда тимер юлы эшен өч тапкыр тикшердек. Бу тикшерүләр кабинетта утырып түгел, бәлки түбәнге звеноларга барып үткәрелде. Әгерже, Юдино бүлекләренең һәм башкаларның җитәкчеләре белән, эшчеләр коллективы белән берлектә тикшереп, конкрет чаралар билгеләнде. Ләкин бу чаралар һич канәгатләнмәслек үтәләләр. Тимер юл җитәкчеләре хәтта аерым карарларны транспорт работникларына җиткермәгәннәр. Өлкә Комитеты 1939 нчы елның 27 нче июлендә тимер юлның капиталь төзелеше һәм урта ремонты турында тикшереп, тиешле карар кабул иткән иде. Пичугин һәм Мандур иптәшләр бу карарны массага, политбүлекләргә һәм коммунистларга җиткермәгәннәр. Тимер юлны төзекләндерү һәм аварияләргә каршы көрәшү һич тә канәгатләнерлек түгел әле.

Өлкә Комитеты үзенең карарында паровоз паркының бик начар эшләвен күрсәткән һәм бу эшне яхшырту өчен практик чаралар билгеләгән иде. Бу карар ничек үтәлә соң? Юдино бүлегендә 1 нче февральгә паровозларның 26 проценты, Әгерже бүлеге буенча 36,48 проценты төзек түгел. Моның төп сәбәбе—ремонтның яхшы сыйфатлы булмавында. Тимер юлда ягулыкка экономия ясау, су белән тәэмин итү һәм башкалар турындагы карарлар да тиешенчә үтәлмиләр.

Иптәш Пичугин тимер юлда яхшы эшләүчеләр күп булуы турында сөйләде. Дөрес, алар бар. Әгәр дә Казан тимер юлы җитәкчеләре, шул исәптән иптәш Пичугин, эшне дөрес оештырсалар, алдынгыларның эш тәҗрибәләрен башкаларга күчерсәләр, стахановчылар саны тагын да күбрәк булыр иде.

Казан тимер юлының аерым пунктларында стахановчылар саны арту урнына кими бара. Мәсәлән, Юдино бүлегендә башта 932 стахановчы бар иде, декабрьдә 877 гә, январьда 855 кә калган.

Җирле промышленностьның эше турында. Җирле промышленность халыкның үсеп бара торган сорауларын канәгатләндерүче зур чыганак булырга тиеш. Бу промышленность өченче бишьеллыкта үзенең производствосын ике тапкыр үстерергә, ассортиментны яхшыртырга тиеш. Иптәш Филимоновка һәм иптәш Быстровка җирле промышленностьны җәелдерү өчен бер нәрсә дә уңайсызламый. Моның өчен средстволар бар, Татарстанның табигый байлыклары да җитәрлек. Ләкин бу эш начар бара. 1939 нчы елны 17 районда промкомбинат төзү эше тәмамланырга тиеш иде, шулардан бер генә комбинат срогына өлгерде.

Җирле промышленностьның начар үсүенә партиянең район оешмалары һәм райсоветлар да гаепле. Аларның күбесе наркоматка ярдәм итмиләр. Кайбыч, Саба, Беренче Май, Тархан һәм башка районнар бу эшкә бигрәк тә җавапсыз карыйлар.

Татнаркомлес эше турында. Партиянең XVIII нче съезды урман промышленностеның артка калуын бетерүне таләп итте. Ләкин Татнаркомлес бу эштә борылыш тәэмин итә алмады. Наркомат җитәкчеләре 1939 нчы елның өченче кварталында ирешелгән уңышлар белән тынычландылар, шуның нәтиҗәсендә дүртенче квартал планы үтәлмәде. Быелның беренче квартал планын үтәү эше дә өзеклектә. 1 нче мартка хәзерләүләр буенча квартал планы 24 һәм ташулар буенча—30 процентка гына үтәлгән. Бу өлкәдә артта калуның төп сәбәбе, барыннан да элек, наркомат җитәкчеләренең стахановчылык хәрәкәтен җәелдерүгә, производствода рационализация кертүгә һәм төп профессияләрнең кадр эшчеләрен дөрес файдалануга контрольлек итмәүләрендә. Агач ташуда стахановча методлар йомшак кулланыла, механикалаштырылган транспортны оештыру эше белән бөтенләй шөгылләнелми.

Юл төзелеше турында берничә сүз. Республиканың юл төзелеше һич канәгатләнмәслек хәлдә. Бу хәл—Татсовнаркомның юл төзелеше идарәсе һәм җирле оешмалар тарафыннан юл төзелешенә большевистик җитәкчелекнең булмавы нәтиҗәсе. Өлкә оешмаларының бурычы—юл төзелеше планын үтәүгә көчне тагын да ныграк туплау. Столбище районының „13 лет Октября" колхозы колхозчыларының инициативасы барлык районнар тарафыннан якланырга һәм ныгытылырга тиеш. Күп районнар бу өлкәдә масса эшен начар оештырганнар әле. Аксубай, Октябрь, Тельман, Чүпрәле районнары юл төзелеше планын 2—4 процентка гына үтәгәннәр.

Өлкә Комитеты промышленность һәм транспорт мәсьәләләре белән аз шөгылләнмәде. Якындагы бурыч—карар чыгару белән генә чикләнмәскә, бәлки ул карарларны тулы үтәүгә партия оешмаларын тагын да ныграк туплаудан гыйбарәт.

Работникларда партия һәм дәүләт җаваплылыгы хисе тәрбияләргә

Совет Контроле Комиссиясенең Татарстандагы уполномоченные иптәш Рундаев речённән

ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм, гомумән, Татарстан партия оешмасының эшен яхшырту өчен әһәмияте зур булган һәм отчет докладында җитәрлек урын бирелмәгән ике мәсьәләгә тукталырга телим.

Татарстанда нефть разведкасы һәм бораулау эше уздырылырга тиешле структуралар 20 урында исәпләнә. Бу пунктларның барсын да тиз арада хәзерләргә һәм промышленность эксплоатациясенә бирергә кирәк. Ләкин бүгенгә әле 3 кенә пунктта (Кама Тамагы, Шөгер, Булдырь) эш башланган. Промышленность разведкасы бары тик Булдырьда гына алып барыла. Бу инде Татарстанда нефтьне эзләп табу һәм чыгару эше XVIII нче съезд карарларын үтәрлек итеп оештырылмаган дигән сүз. Менә тагын фактлар: Татарстан геология тресты 1939 нчы елда Кама Тамагында бораулау эше планын 32 процентка гына үтәде. Бораулау агрегатының җитештерүчәнлеге Кама Тамагы партиясе буенча 26 процент, Шөгер партиясе буенча 33 процент кына булды. 1 метр араны бораулап үтүнең үзенә төшү бәясе Кама Тамагында 88 процентка, Шөгердә 179 процентка кыйммәтләндерелде. Һәр ике партиядә эш вакытының 14,6 проценты гына бораулау эшенә файдаланылган, ә шул ук вакытта 62 процент вакыт эшсез торылган.

Мин монда Татарстан геология тресты һәм аның җитәкчеләренең начар эшләүләре турында әйтеп тормыйм. Ләкин бу мәсьәләдә партиянең Өлкә Комитеты аппаратының эшенә, Татсовнаркомның җитәкчелегенә, партия директиваларының үтәлешен тикшерүнең торышына, Татсовнаркомның һәм күп кенә наркоматларның нефтьчеләргә булышлыгы мәсьәләсенә тукталырга телим.

ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Татсовнаркомның 1939 нчы ел, 17 нче апрель карарында Синявский, Стариков, Черзор, Филимонов, Хәмидуллин, Осинцев һәм Быстров иптәшләргә нефть разведкасы эшен тизләтү буенча нефтьчеләргә конкрет булышлык итәргә тәкдим ителде. Кемгә нәрсә эшләргә кирәклеге карарда ачык язылган иде. Төгәл биш айдан соң, 17 нче сентябрьдә ВКП(б)

Өлкә Комитеты бу карарны кайбер иптәшләрнең үтәмәгәнлекләрен яңадан күрсәтте.

Шул ук вакыт эчендә нефть разведкасы эшен тизләтү турында Татсовнарком тагы ике карар чыгарды. Карарлар күп булды, ә наркомнар һәм өлкә оешмаларының кайбер җитәкчеләре партия директиваларын, Өлкә Комитеты директиваларын үтәмәделәр. Өлкә Комитеты аппараты һәм Совнарком җитәкчелеге биш ай буена югарыдагы директиваларның үтәлешен тикшерүне оештырмадылар, җитәкче работникларның бу мөһим директиваларны үтәүдә дисциплинасызлыкларына юл куйдылар.

Промкооперация турында берничә сүз әйтергә кирәк. Аның еллык отчетына караганда, бу системада 1939 нчы елда валовой продукция эшләп чыгару планы 104 процентка үтәлгән. Беренче карашта бу начар күрсәткеч түгел. Ә менә киң куллану товарлары эшләп чыгаруга килгәндә, мөмкинлекләр зур булуга да карамастан, эш мактанырлык түгел. Промкооперация системасындагы 69 артель 1939 нчы елда планны үтәмәделәр. Алар дәүләткә һәм потребительләргә 13 миллион сумлык товар биреп җиткермәделәр.

Промкооперация системасында производство чималына учет эше гадәттән тыш начар куелган. Шуның нәтиҗәсендә, чималны җинаятле рәвештә артык тоту киң урын алган. Мәсәлән, система буенча 38 тонна йон кирәгеннән артык тотылган. Бу бит әзер продукциягә күчергәндә 20 мең пар киез итек дигән сүз.

Кайбер артельләр Татпромсовет җитәкчелегенең рөхсәтеннән башка чималны читкә саталар. Мәсәлән, „Кызыл Күнче" артеле 26 мең сумлык, „Кызыл Йолдыз" артеле 15 мең сумлык мех кисәкләрен Чкалов шәһәренә сатканнар. Ә шул ук вакытта Татпромсовет җитәкчеләре артельләр өчен чимал җибәрүне сорап көн саен Совнаркомга килеп йөриләр.

Промкооперация эше турында югарыда китерелгән фактлар, СССР Совнаркомының җирле промышленность һәм промысловой кооперациянең эшен яхшырту турындагы һәм киң куллану товарлары эшләп чыгару турындагы карарының үтәлешенә Татсовнаркомның системалы контрольне тәэмин итмәвен күрсәтәләр. Татсовнаркомның мондый эш стиле работникларда дәүләт җаваплылыгын тәрбияли алмый.

XXI нче Өлкә Конференциясе ВКП(б) Өлкә Комитетының яңа составыннан партия директиваларын большевикларча үтәргә теләмәүче хәсрәт җитәкчеләргә каршы кискен рәвештә көрәшүне таләп итәргә тиеш. Өлкә Комитетының яңа составы үзенең киләчәк эше өчен партия директиваларының үтәлешен системалы тикшереп баруны тәэмин итәрлек, работникларыбызның партия һәм дәүләт алдындагы җаваплылыкларын күтәрерлек чаралар билгеләргә тиеш.

Агротехника чараларын дөрес оештырырга кирәк

ВКП(б) ның Ютазы райкомы секретаре иптәш Гафиятуллин речённән

Отчет чоры эчендә партиянең Ютазы район оешмасы үзенең сафларын иң яхшы, алдынгы кешеләр исәбенә үстерү буенча шактый эш үткәрде.

Бу чор эчендә районда партия сафларына 200 дән артык кеше кабул ителде, 12 башлангыч партоешма оештырылды, районда хуҗалык эшләрен политик бурычлар белән бергә бәйләп алып бару шактый яхшырды.

Культура төзелеше өлкәсендә ирешелгән уңышларыбыз да зур гына. Хәзер безнең районда 4 урта мәктәп, 9 тулы булмаган урта мәктәп, 30 башлангыч мәктәп бар.

Шуның белән бергә, безнең партоешманың эшендә зур гына кимчелекләрне дә күрсәтеп үтәргә кирәк. Беренчедән, без әле югары иген уңышы алу буенча иптәш Сталин куйган бурычны тулысынча үти алмадык. 1939 нчы елны безнең районның колхозлары түбән уңыш алдылар. Моның сәбәбе—табигатне алдынгы агротехникага, көчле машина техникасына буйсындыруга әле өйрәнеп җитмәвебездә, районны кирәкле агрономия көчләре белән вактында тәэмин итмәвебездә.

Безнең районда 70 колхоз бар. Аларның 85 мең гектардан артык чәчү мәйданнары бар. Ә районда махсус урта белемле ике генә агроном бар. Аларның берсе район җир бүлегендә, икенчесе МТС та эшли. Бу ике агроном районның 70 колхозына тиешле агрономия ярдәмен тәэмин итә алармы? Билгеле, тәэмин итә алмыйлар. Авыл хуҗалыгы белгечләре булмаган яки бик аз булган районнарны белгечләр белән тәэмин итү эшендә Татсовнарком һәм Татнаркомзем нинди чаралар күрделәр һәм күрәләр, авыл районнарына белгечләр җибәрү турында „Правда" ның чакыруын һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының карарын алар ничек үтиләр соң? Минемчә, бу төп мәсьәләдә безнең Татарстанның өлкә оешмалары, аерым алганда Татарстан Совнаркомы һәм Татнаркомзем, әле һаман канәгатләнмәслек эшләүләрен дәвам иттерәләр. Һич шиксез, районны авыл хуҗалыгы кадрлары белән, белгечләр белән тәэмин итү буенча эшлекле чаралар күрелергә тиеш.

Башка районнар белән чагыштырганда, безнең районда терлекчелек эше күбрәк алга киткән. Хәзер безнең районда 35 меңнән артык терлек бар. Без ел саен терлек азыгы үләннәрен чәчүне арттырырга рөхсәт сорыйбыз. Ләкин безнең сорау канәгатләндерелми. Мәсәлән, 1938 нче елны без 2,5 мең гектар сорадык, ә безгә 2 мең гектар гына бирделәр. Икенчедән, районның 3 әр меңнән артык терлекләре булган зур колхозларында су белән тәэмин ителүнең начар хәлдә булуы күзгә бәрелә. Ләкин безнең бу өлкәдәге омтылышларыбыз моңа кадәр уңышсыз тәмам булдылар. Шуннан соң без, артезиан коелары төзүдә генә булса да безгә ярдәм күрсәтүне сорап Наркомземга һәм Татарстан Совнаркомына мөрәҗәгать иттек. Ләкин, ике елдан артык инде вәгъдәләрдән башка ярдәм ала алганыбыз юк.

Татарстан Наркомземы җитәкчелеге турында

ВКП(б) ның Алабуга райкомы секретаре иптәш Петров речённән

Мин Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариатының эше турында тукталып үтәргә телим.

Наркомзем җитәкчелегендә зур гына кимчелекләр бар. Районнарга һәм МТС ларга җитәкчелек итүдә ул сугышчан штаб булып әверелгәне юк әле. Наркомзем аерым районнарның һәм МТС ларның сорауларына колак салып җиткерми. Мисаль өчен Макыл МТС ын алып карыйк. 1940 нчы елны бу МТС ка 10 данә газогенераторлы тракторлар бирүне планлаштырганда, ягулык мәсьәләсен бөтенләй исәпкә алмыйлар. Наркомзем шушы көнгә кадәр ягулык турында бер төрле дә чара күрми. Татарстан Госпланына карата да шул ук сүзне әйтергә кирәк.

Икенче бер факт. Макыл МТС ында ремонт мастерское булмау эшкә зур комачаулык китерә, артык расходлар тотуга алып бара. Һәрбер подшипник өчен машинаны Алабугадан Чаллы МТМ ына алып бару уңайсыз хәл. Без Макыл МТС ында ремонт мастерское оештырган идек. Бөтен эш шлифовка станогына барып терәлде. Бу турыда Наркомземга берничә тапкыр мөрәҗәгать итәргә туры килде. Ләкин шушы көнгә кадәр бер төрле дә нәтиҗә күренми. Шлифовка станогы бирелсә без елына ким дигәндә 30—40 мең сум экономия ясый алачакбыз.

Район җир бүлекләрендә агрономнар җитешмәүне күп ишетергә туры килә. Шулай булуга карамастан, аларның күбесе төрле учреждениеләрдә һәм уку йортларында утыралар. Наркомзем бу әһәмиятле эшкә дә тиешенчә игътибар бирми.

Без үзебезне аклый алмыйбыз, әлбәттә. Алабуга районының җитәкче оешмалары үзләренең эшләрен ВКП(б) ның XVIII нче съезды таләп иткәнчә яңа баштан оештыра алганнары юк әле. Без колхозларга дифференциаль рәвештә якын килә белмибез, авыл хуҗалыгы алдынгыларының үрнәкле эшләрен күреп җиткермибез.

Район җитәкчеләренең кайберләре теге яисә бу җитешсезлекләр өчен колхоз председательләрен эштән алу белән генә чикләнеп, җиңел юлга басалар. 5 ай эчендә безнең районда 12 колхоз председателе эшеннән алынды. Кайбер колхозларда бу вакыт эчендә өчәр-дүртәр председатель алмашынды инде.

Отчет чоры эчендә безнең партия оешмаларыбыз шактый үсте. 1939 нчы елны ВКП(б) сафларына 275 кеше кабул ителде. ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң

безнең районда 245 кеше төрле җитәкче эшләргә күтәрелде. ВКП(б) члены иптәш Родионов райкомның хәрби бүлеге мөдире итеп, иптәш Кузнецов Союзплодоовощ управляющие итеп, алдынгы шофер иптәш Рәхмәтуллина МТС директоры урынбасары итеп күтәрелделәр. Бу иптәшләр үзләренә тапшырылган эшне намус белән башкаралар. Күтәрелгән работникларга булышлыкны тагын да көчәйтергә кирәк.

Алабуга районында 10 промартель бар. Аларның күбесе үзләренең планнарын арттырып үтәделәр. Промартельләрдә өстәмә продукция эшләп чыгару өчен зур мөмкинлекләр булуын аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк. Моның өчен артельләрдә яңа цехлар оештыру таләп ителә. Бу турыда без Татарстан Җирле Промышленность Халык Комиссариатына, Таткоопинсоюзга һәм башка оешмаларга мөрәҗәгать иттек. Ләкин алар урыннардагы промартельләргә оператив һәм конкрет җитәкчелекне тәэмин итмиләр. ВКП(б) Өлкә Комитеты бу оешмаларга карата чаралар күрергә тиеш.

Отчет-сайлау җыелышларында ачылган җитешсезлекләрне ашыгыч бетерик

ВКП(б) ның Апас райкомы секретаре иптәш Хәйруллин речённән

Партиянең Татарстан оешмасы үзенең сафларын үстерү һәм ныгыту буенча отчет чоры эчендә күп кенә эшләр эшләде. Без моны партия сафларының алдынгы эшчеләр, колхозчылар һәм совет интеллигенциясе исәбенә үсүендә дә күрәбез. Мондый уңышлы нәтиҗәләр безнең районда да бар. Партиянең Апас район оешмасы отчет чорында 100 процент үсте. Ләкин партия сафларын төп профессия кешеләре исәбенә үстерү эше бездә начар тора әле. Мәсәлән, безнең оешмада тракторчылар партиягә кабул ителгәннәрнең 4 кенә процентын, комбайнчылар—2,1 генә процентын, хатын-кызлар 11 генә процентын тәшкил итәләр.

Без еш кына, җитешсезлекләрне һәм ялгышларны икрар итү белән генә чикләнәбез. Җитешсезлекләрне һәм ялгышларны икрар итү генә җитми, аларны бетерү өчен конкрет чаралар күрергә кирәк.

Безнең эшебездәге төп җитешсезлекләрнең берсе партияле массалар алдында отчет ясап тору практикасын кулланмауда. Әгәр райком әледән-әле отчет ясап барган булса, коммунистлар райкомның эшендәге җитешсезлекләрне үз вактында күрсәткән булырлар иде. Шуңа күрә дә коммунистлар отчет биреп торуның кирәклеген бик урынлы куйдылар һәм устав таләп иткәнчә эшләргә кирәклекне күрсәттеләр. Иптәш Сталин безне массаның тавышына колак салырга өйрәтә. Партия оешмалары җитәкчеләренең бурычы отчет-сайлау җыелышларында күрсәтелгән җитешсезлекләрне ашыгыч бетерү өчен җидди чаралар күрүдән гыйбарәт.

„Красная Татария" газетасы редакциясенең эше турында берничә сүз. Бу редакциядә бөтенесе дә яхшы торамы? Юк, минемчә, алай түгел. „Красная Татария" газетасы эшлекле ярдәм күрсәтү урнына, кай чакта урынсызга бәйләнү белән шөгылләнә, дөрес булмаган фактлар язып чыга. Мәсәлән, 23 нче февральдә „Красная Татария" газетасында „Апас районында үтәлешне ничек тикшерәләр" дигән мәкалә урнаштырылды. Мәкаләнең авторы — „Красная Татария" газетасының махсус хәбәрчесе иптәш Кузьмин райкомны, декабрь пленумы карарларының үтәлешен тикшерү буенча райком партиянең район активын чакырды һәм анда бөтен эшне бутады, дип гаепли. Без декабрь пленумы карарларының үтәлешен тикшерү буенча районда актив җыелышы чакырмаганлыгыбызны әйтергә тиешбез. Дөрес, без пленум карарларының үтәлешен тикшердек, ләкин аның йомгакларын активта түгел, бәлки бюрода һәм урыннарда, башлангыч оешмаларда куйдык.

„Красная Татария" газетасының махсус хәбәрчесе райкомны партиянең Апас районы оешмасы колхозчылар исәбенә начар үсә дип гаепли. Бу һич тә дөрес түгел. Отчет чоры эчендә безнең оешма 100 процент үскән булса, шуның 60 процентын колхозчылар тәшкил итәләр. Шушыннан соң партиянең Апас районы оешмасы колхозчылар исәбенә үсми дип ничек әйтергә?

Ә ни өчен шундый нигезләнмәгән гаепләү килеп чыккан? „Красная Татария" газетасы хәбәрчесе районда көн ярым гастрольлек иткән дә, мәкалә язган. Хәтта ул райком секретареның фамилиясен дә белмәгән: Хәйруллин урнына, райком секретарьлары арасында бер кайчан да булмаган Абдуллинны гаепләргә маташкан. Ә редактор иптәш Анушкин бу хәбәргә бөтенләй игътибар бирмәгән.

Газета тарафыннан мондый „ярдәм" яхшыга алып бармый. „Красная Татария" газетасы редакциясе моны истә тотарга, материалларның дөреслегенә, нигезле булуына игътибарны көчәйтергә тиеш.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ҺӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Югары уңыш өчен, терлекчелекне үстерү өчен!

Ворошилов райкомы секретаре иптәш Сәмигуллин реченнән

Отчет чорында промышленность һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә, шулай ук партиянең эчке эшләре буенча безнең уңышларыбыз бар, әлбәттә. Мин аларга тукталмыйча, кайбер кимчелекләр һәм аларның сәбәпләренә тукталам.

ВКП(б) Өлкә Комитетының отчетыннан күренгәнчә, безнең Татарстан республикасы узган елда югары уңышлар [illegible] алды. Бу—Татарстан партия оешмасы эшендә бик зур кимчелек. Без моны киләчәктә кабатламаска, авыл хуҗалыгын алга җибәрү өчен барлык чараларны күрергә һәм алдагы елда югары иген уңышы ялап алуга ирешергә тиешбез.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшнең үз вакытында, кыска срокларда үткәрелүе—иген уңышын күтәрүдә хәл иткеч шартларның берсе. Партиянең XVIII нче съездында иптәш Андреев моның шулай икәнен конкрет фактлар мисалендә күрсәтте. Ләкин бу мәсьәләдә без начар эшлибез әле. Мәсәлән, язгы чәчүне 5—6 көн эчендә үз иту бурычын үтәүдән без ерак торабыз әле. Моның өчен иң беренче чиратта социалистик ярышны сүздә түгел, эштә оештырырга кирәк. Фактлар исә ВКП(б) Өлкә Комитетының, Наркомземның социалистик ярыш белән җитәрлек шөгыльләнмәүләре турында сөйлиләр.

Иген уңышын күтәрү өчен көрәштә трактор паркының эше аеруча зур әһәмиятле. Трактор паркы яхшы эшләгән урында авыл хуҗалыгы эшләре үз вакытында үтәлә. Мәсәлән, безнең районда 3 МТС бар, аларның икесе яхшы эшли, һәр елны планнарын арттырып үтиләр. Бу ике МТС хезмәт күрсәткән участкылар 1939 нчы елда, артта калучы Кадрәк МТС сы хезмәт күрсәткән участкыларга караганда, иген уңышын ике тапкыр югары алдылар. Бездә Мин Актаныш һәм Зирекле МТС ларын күздә тотам. Аларның эш тәҗрибәләрен башка МТС ларга күчерү эше белән кем дә булса шөгыльләнәме соң? Минемчә, Өлкә Комитетының бу мәсьәләдә кайбер бүлеге дә, Наркомзем да моның белән шөгыльләнмиләр. Кайбер МТС ларның начар эшләүләренә төп сәбәп аларның механизатор кадрлар хәзерләү эше белән шөгыльләнмәүләрендә. Өлкә Комитеты киләчәктә моңа аерым игътибар итәргә тиеш.

Авыл хуҗалыгында иң әһәмиятле тармакларның берсе—терлекчелектән күпме продукция алынганлыгы һәм мәсьәле терлекләр белән тәэмин ителүнең торышы турында отчет докладында аз әйтелде. Ә безнең бу тармакта эшләр бик начар. Эшебез канәгатьләнерлек тормый. Без киләчәктә терлекчелектән күп продукция алу өчен, терлекләр санын арттыру өчен бик нык эшләргә тиешбез.

Казан юлын алдынгылар сафына

Казан тимер юлы прокуроры иптәш Куренков реченнән

Большевиклар партиясенең XIV-XV нче съездларында иптәш Сталин тимер юл транспортының начар эшләвен әйтеп үткән иде. Бу вакытларда тимер юл транспорты йөк ташу планын үти алмады, социалистик хуҗалыгыбызның үсешенә тоткарлык ясап килде. 1935 нче елны транспортка Лазарь Моисеевич Каганович килгәннән соң, иптәш Сталинның көндәлек ярдәме белән транспорт социалистик хуҗалыкның алдынгы тармакларыннан берсе булып әверелде. Бу шуннан күренә ки, 1935—1939 нчы елларда тимер юл транспортының яхшы эше Совет хөкүмәте тарафыннан 3 тапкыр күрсәтелеп үтелде. Транспортның алдынгы кешеләре хөкүмәт тарафыннан бүләкләнделәр.

1939 нчы елның 23 нче ноябрендә Совет хөкүмәте күп кенә тимер юлларның алдынгыларын бүләкләде. Бу көнгә Казан тимер юлы канәгатләнерлек эшләми иде. Шул сәбәпле безнең юлның аерым кешеләре генә бүләкләнделәр.

Казан тимер юлы йөк төяү һәм бушату планын, техник тизлек, вагон оборотлары планын үтәми, социалистик хуҗалыкка күп зарар китерә торган крушениеләр һәм авариялар тәмам бетерелмәгәннәр. Крушениеләрнең күпчелеге юлның төзек булмавы, кадрларны сайлап ала белмәү аркасында булалар. Казан тимер юлының кыр станцияләрендә эшләүче эшчеләре арасында политик-тәрбия эшләре тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган. Конференциядә чыгып сөйләүче Пичугин һәм Мандур иптәшләр бу турыда әйтергә тиешләр иде. 1939 нчы ел буена политбүлек работникларыннан бер генә кеше дә участкыларда булмаган, алар алдынгы ударниклар торган казармаларда да булмаганнар.

Казан юлы җитәкчеләре юлга ремонт эшен һәр яктан яхшыртырга тиешләр. Бездә юл начальнигының Пудонин дигән бер ярдәмчесе бар. Ул юлның төзеклеге өчен турыдан-туры җавап бирергә тиеш. Ләкин Пудонин дистанцияләргә бюрократларча гына, бик сирәк чыга. Ул мәсьәләләрне күбрәк транспорт командирлары киңәшмәсендә генә хәл итә.

Казан юлы йөк төяү планын үтәми. Ләкин, шуның белән бергә, мин клиентлар турында әйтеп үтәргә уйлыйм. Алар тимер юлда йөк төяү һәм бушату буенча үз карашларын үзгәртергә тиешләр. Мәсәлән, Ленин исемендәге завод йөкне үз вакытында бушатмавы өчен декабрь аенда гына да 158 мең сум штраф түләде. Шул ук завод вагоннарны хәрәкәтсез тотуы өчен ике ел буена 2 миллион сум штраф түләргә мәҗбүр булды. Йөкне үз вакытында төяү һәм бушату өчен үз юлын үзгәртеп корырга аңа бары тик 200 мең сум акча кирәк иде.

Тимер юл транспорты эше—ул, бөтен ил эше. Мин уйлыймын, юлның партия оешмасы, район партоешмасының һәм Өлкә Комитетының көндәлек ярдәме белән, Казан тимер юлын алдынгылар сафына чыгару өчен барлык чараларны күрер.

Революцион законлылыкны тайпылышсыз тормышка ашырырга

Республика прокуроры иптәш Перов реченнән

Делегат иптәшләр!

Прокуратура органнарында эшләүче коммунистлар отчет чорында үзләренең нәрсә эшләгәннәре турында партиянең өлкә конференциясенә белдерүне үзләренең бурычы итеп саныйлар. Мин, алар исеменнән чыгып сөйләүче булам, шул уңай белән, 1938 нче елның башына республика прокуратурасы органнарында булган хәлгә кыскача характеристика бирүне кирәк дип саныйм.

Элекке җитәкчелекнең провокацион эшчәнлеге нәтиҗәсендә прокуратураның ул вакыттагы эш практикасы активны, башлыча совет һәм колхоз активын, массовый рәвештә гаепләү, волокита, эшнең үз агымына куелуы һәм эш сыйфатының түбән булуы белән характерлана иде. Прокуратура органнары революцион законлылык өчен, җинаятьчелеккә каршы көрәштә чын инициатор һәм оештыручы булсыннар өчен, барыннан да элек мондый практиканы, корткычлык нәтиҗәләрен тамырыннан бетерергә кирәк иде. Отчет чорында прокуратура работниклары бу юнәлештә шактый эш башкардылар.

Волокитаны бетерүдә сизелерлек адым ясалды. Тикшерелмәгән эшләрнең саны 1938 нче ел белән чагыштырганда, хәзер 4 тапкыр кимеде. Тикшерү эшләренең шактый өлеше буенча закон белән билгеләнгән срокларда үткәрелә.

Без ирешелгән уңышларга таянып, инде барсын да эшләдек дип әйтә алабызмы соң? Юк, моны әйтеп булмый, чөнки республика прокуратурасы органнарының эшендә җитешсезлекләр бик күп әле.

Җинаятчелеккә, революцион законлылыкны бозучыларга каршы көрәш тиешле принципиаль югарылыкта тормый. Район прокурорлары да, республика прокуратурасы да җитәрлек инициатива һәм оештыручылык роле күрсәтмиләр. Сан һәм сыйфат буенча да прокуратура органнарының эше канәгатләнерлек түгел. Эш практикасында күп кенә хәлләрдә нигезсез гаепләүләргә юл куела, шул ук вакытта чын җинаятчеләр җәзага тартылмыйча калалар. Тикшерү эше турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Прокуратура работникларының җәмагатчелек белән элемтәсе йомшак. Җәмагатчелек белән элемтәне ныгытуда, җәмагатчелекне революцион законлылык рухында тәрбияләүдә әһәмияте зур булган суд процесслары прокурорлар тарафыннан җитәрлек файдаланылмыйлар, алар принципиаль-политик югарылыкта һәм киң катлау хезмәт ияләре массасының катнашы белән үткәрелмиләр, ә бәлки кабинет тәртибендә генә үткәрелә.

Растратчикларга, урлаучыларга һәм аларның булышчыларына каршы, социалистик милекне, дәүләт һәм кооператив-колхоз милкен урлаучыларга, төрле тәстәге растраталарга юл куючыларга каршы көрәштә прокуратура органнары һаман да көчен тиешенчә күрсәтмиләр әле. Прокуратура работниклары җинаятьләрне вакытында ачып, җинаятьчеләрне һәм аларга булышчыларны закон нигезендә җавапка тартасы урында, еш кына, аларга карата либеральлек күрсәтәләр.

Кайбер урыннарда прокуратура работникларының, шулай ук совет һәм партия оешмаларының эш практикасында әһәмияте зур булмаган һәм шунлыктан уголовный чаралар кулланырга тиеш булмаган, бәлки административ чаралар белән генә чикләнергә мөмкин булган гаепләр өчен авыл - колхоз активын массовый рәвештә җавапка тартуларга юл куела. Моңа Мөслим районы характерлы мисаль булып тора. Бу районда барлыгы 63 колхоз председателе бар. Район җир бүлеге 1939 нчы елда гына да колхоз председательләре өстеннән прокуратурага 80 „материал" биргән. Димәк, җир бүлегенең „акыл ияләре" берничә председательне икешәр тапкыр хөкем иттерергә уйлаганнар (!).

Хулиганлыкка каршы көрәш турында берничә сүз. Без хулиганлыкка каршы көрәш алып барабыз, хулиганнарны хөкем итәбез, аларның байтагын ирektән мәхрум итәбез. Ләкин хулиганлыкны тудыручы сәбәпләр белән җитәрлек кызыксынмыйбыз. Бу категория җинаяткә анализ ясаганда, барыннан да элек, хулиганнарның 50 проценты 25 яштән үтмәгән кешеләр тәшкил иткәнлеген күрәбез. Шул уңай белән безнең комсомол оешмасының эше турында сорау туа. Ул, хулиганлыкка каршы көрәш буенча нәрсә эшли соң, аның тәрбия эше нинди югарылыкта тора? Хулиганлык турында прокуратура органнарында булган материаллар һәм күп сандагы фактлар комсомол оешмасы тарафыннан комсомолецлар һәм союздан тыш яшләр арасында алып барылырга тиешле тәрбия эшенең канәгатләнмәслек булуы турында сөйлиләр. Комсомол оешмалары хулиганлыкка каршы көрәштә инициатор булырга һәм шуның белән прокуратура органнарына булышлык күрсәтергә тиешләр.

Прокуратура работниклары—партиябезнең алдынгы отрядларының берсе буларак, революцион законлылыкны тайпылышсыз тормышка ашырырга тиешләр.

Кичекмәстән бетерелергә тиешле җитешсезлекләр

ВКП(б) ның Лаеш райкомы секретаре иптәш Огольцов реченнән

Иптәшләр!

Партия сафларын үстерү мәсьәләсендә ВКП(б) нын XVIII нче съезды карарларын һәм иптәш Сталинның күрсәтмәләрен үтәү буенча партиянең Лаеш район оешмасы зур гына уңышларга ирешte. Мәсәлән, 1938 нче елда булып үткән отчет-сайлау җыелышлары вактында районда 17 башлангыч партоешма, 7 кандидатлар группасы булып, аларда 115 коммунист исәпләнсә, хәзер 30 партоешма, 5 кандидатлар группасы исәпләнә һәм коммунистларның саны 325 кешегә җитте.

Ләкин бу уңышлар белән без мактана алмыйбыз әле. Чөнки райондагы 65 колхозның 54 ндә партоешмалар юк. Моның сәбәбе ачык: райком тарафыннан бу колхозларга игтибар җитәрлек түгел. Райком инструкторлары, пропагандистлары аларда сирәк булалар һәм колхозчылар арасында политик-масса эшләрен тиешенчә куюю эшен тәэмин итмиләр.

Партия сафларын регулярләштерү, аны төп профессия кешеләре хисабына үстерү мәсьәләсенә дә райком җитәрлек игтибар итмәде. Мәсәлән, партиягә кабул ителгәннәрдән эшчеләр 16, крестьяннәр 80, комбайнчылар 2, тракторчылар 5 кеше, ә хезмәткәрләр 117 кеше булу моны бик ачык күрсәтә. Бу мәсьәләдә ВКП(б) Өлкә Комитеты оештыру-инструкторлык бүлегенең, аның җитәкчесе иптәш Жуковның да безгә җитәкчелеге җитәрлек булмады. Гомумән, безнең протоколлар буенча кимчелекләребез турында иптәш Жуков һәм ул җитәкчелек итә торган бүлектә эшләүче работниклар тарафыннан



безгә бер төрле дә күрсәтмәләр булмады.

Авыл хуҗалыгы мәсьәләсендә безнең эшләр тагын да начар. Соңгы ике елда Лаеш районы иң артта калучы районнарның берсе булып килде. Дәүләт йөкләмәләре үтәлми, иген уңышы алу кимеде. Ни өчен? Чөнки партиянең район оешмасы агротехника чараларын тормышка ашыру өчен җидди рәвештә көрәшмәде. 1940 нчы елгы язгы чәчү эшләренә хәзерлекнең торышы да начар. Кар тоту планы 80, кырга тирес чыгару планы 40, көл җыю планы 50 процент кына үтәлгән. Чәчү орлыгы мәсьәләсе тагын да начар тора.

Совхозтрест кадрлар сайлап алганда кешеләрнең политик һәм эшкә сәләтле булулары ягына бөтенләй игтибар бирми булса, кирәк. Мәсәлән, Совхозтрест үткән елның октябрь аенда безгә ветврач җибәрде. Бу ветврач терлекләрнең үлүен киметү өчен ашыгыч чаралар күрү урнына, яңа туган дуңгыз балаларына марганцовка ашаткан һәм аларның үлүләренә үзе сәбәпче булган.

Биредә, иптәш Динмөхәметов авыл һәм район советлары башкарма комитетларының сайлаучылар алдында отчет бирергә тиешлекләре турында әйтте. Ә сайлаучылар алдында Верховный Совет депутатларының отчет бирүләре ничек торышына бөтенләй тукталмады. Ачык әйтергә кирәк: Верховный Совет депутатлары үзләре сайланган округлардагы сайлаучылар алдында бүгенгә кадәр отчет ясаганнары юк әле. Бу—зур кимчелек. Иптәш Динмөхәметов бу кимчелекне бетерү чарасын күрергә тиеш. Безнең совет законында күрсәтелгәнчә, депутатларны сайлаучылар алдында отчет бирергә мәҗбүр итәргә кирәк.

Издательствога җитәкчелекне көчәйтергә

Татгосиздат управляющие иптәш Тенчурин реченнән

Татарстан Дәүләт Издательствосы Татарстан халык хуҗалыгының артта калган участкыларыннан берсе булып тора. Менә Татгосиздатның 1939 нчы елдагы эше. Китап продукциясе планы 86,9 процентка һәм тираж планы 95,4 процентка үтәлгән. Китап продукциясе һәм тираж планының үтәлмәве Татгосиздат эшендә гаят зур кимчелек булып тора. Ләкин, үткән еллар белән чагыштырганда, Татгосиздатның 1939 нчы елгы эшендә кайбер яхшыру сизелә. Кәгаз, идарә расходларын киметү нәтиҗәсендә, Татгосиздат 1939 нчы елда 155 мең сум экономия бирде.

Татгосиздат 1939 нчы елда дәреслекләр чыгару планын үтәде. Татгосиздат работниклары коллективы марксизм-ленинизм классиклары хезмәтләрен һәм башка төрле әдәбиятны (художество, балалар әдәбияты, авыл хуҗалыгы, хәрби) 1939 нчы елда шактый күп чыгарды. Билгеле, эчке рессурслардан тулысынча файдаланганда, кәгаз фонды планын 100 проценты белән үтәгәндә һәм эшне яхшыртканда Татгосиздат коллективы тагын да яхшырак күрсәткечләр бирүгә ирешә алыр иде. Ләкин без бик начар эшләдек. Эшнең сыйфаты түбән булуында дәвам итә әле. Татгосиздат работниклары коллективының идея-политик дәрәҗәсе тиешле югарылыкта түгел. Авторлар һәм редакторлар марксизм-ленинизм теориясе белән җитәрлек дәрәҗәдә кораллану, үз белемнәрен күтәрү өстендә йомшак эшлиләр.

Кайбер авторлар дәреслекләрне төзегәндә яңа политик вакыйгаларне искә алмыйлар. Мәсәлән, яңа төзелгән уку китабында Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең героик җиңүләре, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссиянең 13 миллион халкының азат ителүе, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең гаят зур әһәмияте, иптәш Сталинның 60 еллыгы кертелмәгән. Биредә издательство работниклары да гаепле, билгеле. Ләкин Татнаркомпросның гаебе биредә зуррак, чөнки китапка заказ бирүче булуына да карамастан, аның расланган программасы да юк. Наркомпрос башта китап чыгара, аннан соң чыккан китапларга карап программа төзи. Моны Наркомпросның зур кимчелеге дип әйтергә кирәк.

Совнаркомның Татгосиздатка җитәкчелеге канәгатләнерлек түгел дип әйтергә кирәк, биредә кайбер мәсьәләләргә җидди рәвештә карамыйлар. Камиль Якуб исемендәге китап фабрикасының цинкография цехын Совнарком Александров исемендәге типографиягә бирде. Фабрика бу цехтан башка яши алмый. Бу ялгыш карарны төзәтергә кирәклеге турында РСФСР һәм СССР Совнаркомнарының күрсәтмәләре булуга да карамастан, Тынчеров һәм Сөләйманов иптәшләр үз хаталарын төзәтергә теләмәделәр.

Тәнкыйт йөзеннән туп-туры әй-

тергә кирәк. Совнарком председателе урынбасарлары Киселев һәм Сөләйманов иптәшләр аерым мәсьәләләргә җидди карамыйлар. Алар, ачык итеп әйткәндә, аерым мәсьәләләрне үзләре генә хәл итә алмыйлар. Мәсьәләне башта консультантлар хәл итәләр. Иптәш Сөләйманов кискен түгел, һичбер вакытта да тулы җавап бирми, ә иптәш Киселев артык кызып китүчән.

Районнардагы типографияләрнең һәм район газеталарының нинди хәлдә булуларын без бик яхшы беләбез. Боларга җитәкчелек итү эшен Казанда туплау турында күп сөйләнде инде. Ләкин бу мәсьәләнең дә хәл ителгәне юк әле. Партия Өлкә Комитетының яңа составы бу мәсьәлә белән җидди шөгылләнергә тиеш.

МТС һәм нефть турында

Шөгер районы, „Кызыл орден" колхозының башлангыч партоешма секретаре иптәш Зиннуров реченнән

Иптәшләр! Мин МТС эше һәм Шөгер нефтесе мәсьәләләренә туктальп үтәргә телим. ВКП(б) Өлкә Комитетының кайбер бүлекләре эшендә булган җитешсезлекләр Шөгер райкомы эшендә дә бар. Райкомның оештыру-инструкторлык һәм кадрлар бүлекләре башлангыч партоешмалар белән элемтәне начар тоталар, аларның безгә ярдәм итүләре җитәрлек түгел. Шуның аркасында кайбер колхозларда масса һәм оештыру эшләре бик йомшак куелган.

Аннан соң иптәш Зиннуров Шөгер МТС ы эшенә кагылып болай ди:

— Безнең МТС үзенең начар эшләве аркасында 1939 нчы елның производство планын бары 59 процентка гына үтәде. МТС ның җитәкче работниклары кадрлар белән җитәрлек эш алып бармыйлар, тәрбия эшләренә әһәмият бирмиләр. Колхозлар белән төзегән договорларның үтәлеше өчен кайгыртучанлык күрсәтмиләр, алардан договорларны үтәүне районның җитәкче оешмалары да таләп итмиләр.

— Шөгер нефте мәсьәләсенә килгәндә,—ди иптәш Зиннуров,— геологик-эзләнү эшләре башта ук яхшы үткәрелгән булса, нефть табу эше инде шактый алга киткән булыр иде. Бораулау эшенең канәгатләнмәслек хәлдә торуы бу эшкә Татарстан Совнаркомының җитәкчелеге йомшак булудан килә. Шөгердә нефть бар, аны табу эшен ашыктырырга, Шөгерне Татарстанның промышленность районына әверелдерергә кирәк.

ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турында чит ил матбугаты

ИТАЛИЯ

РИМ, 14 март. (ТАСС). Италиянең бөтен матбугаты СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрне эре хәрефләр белән басып чыгарды. Газеталар договор турындагы ТАСС телеграммасын, договорның текстын һәм договорга кушымта ителгән протоколны тулысы белән урнаштырдылар. Шул ук вакытта матбугат бу вакыйгага зур мәкаләләр багышлап язды. Бу мәкаләләрдә СССР ның хәрби стратегия ягыннан гаять зур уңышы күрсәтелә. Мәкаләләрдә, Финляндия хөкүмәтенең, совет шартларын кабул итүе яхшы дип табыла.

„Трибуна“ газетасы конфликтның бетерелүеннән канәгатьләнүен белдерә.

„Лаворо фашиста“ газетасы СССР ның стратегия позицияләренең ныгуын күрсәтеп үтә.

БОЛГАРИЯ

СОФИЯ, 14 март. (ТАСС). СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрләр Болгария матбугатында үзәк урын алып торалар. Матбугат бу договорга СССР ның тынычлыкны сөюен күрсәтә торган яңа дәлил, дип бәя бирә.

Барлык газеталар беренче битләрендә договорның һәм протоколның тулы текстын басып чыгардылар.

Газеталар Сталин һәм Молотов иптәшләрнең рәсемнәрен урнаштырдылар. Договорның текстын газеталар „СССР белән Финляндия арасында солых“, „Совет дипломатиясенең гаять зур уңышы“, „Барлык фронтларда сугыш хәрәкәтләренең тукталуы“ һ. б. дигән башлар астында басып чыгаралар.

Договор турында Болгария җәмагатьчелеге һәм журналистлары иң җанлы рәвештә фикер алышалар. Күп кенә күренекле эшлеклеләр, солых төзү белән СССР ның гадел хәрәкәт ясаганлыгын һәм үзенең тынычлыкка омтылуын тагын бер тапкыр раслаганлыгын күрсәтәләр. Журналистлар договорны Совет тынычлык политикасының гаять зур җиңүе дип язалар. Газеталар, СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү сугыш уты кабызучыларга нык удар ясый, диләр.

БЕЛЬГИЯ

БРЮССЕЛЬ, 14 март. (ТАСС). Бельгия газеталары солых договорын игълан итү белән бер рәттән „Правда“ газетасының баш мәкаләсеннән өзекләр дә басып чыгардылар. „Метрополь“ газетасы „Совет тынычлык политикасының яңа җиңүе“ исемле мәкалә басып чыгарды.

РУМЫНИЯ

БУХАРЕСТ, 14 март. (ТАСС). Кичә кичке һәм бүген көндезге газеталар СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договорының текстын һәм аңа аңлатуларны эре хәрефләр белән басып чыгардылар.

Барлык газеталар Сталин, Молотов һәм Ворошилов иптәшләрнең портретларын урнаштырдылар.

„Семналул“ газетасы болай дип яза: „Советлар Союзы башта ук үз алдына Финляндияне кол итү бурычын куймаганлыгын белдерде. Договор төзелү моның дөрес булганлыгын күрсәтә“. Аннары газета, Европаның төньягында тынычлык урнаштыруның Европада гомуми хәл өчен зур нәтиҗәләргә китерәчәген күрсәтеп үтә.

АКШ та президент сайлау алдыннан

НЬЮ-ЙОРК, 14 март. (ТАСС) АКШ ның эчке политик интереслары хәзер президент сайлауга юнәлдерелгән.

Демократлар партиясе Рузвельтның үзенең кандидатурасын өченче тапкыр куярга теләге бармы-юкмы икәнлеге турында белдерү ясавын көтә. Рузвельт, әгәр теләсә, [illegible]

Президентлык постына [illegible] вице-президент Гарнер тора.

Гарнер хәзер 71 яшендә, ләкин шундый карт булуына да карамастан, ул зур активлык күрсәтә. Гарнер — зур җир биләүче, ачыктан-ачык реакционер. Тышкы политика мәсьәләләрендә Гарнерның нинди позициядә торуы бик үк мәгълүм түгел.

Уйлауларга караганда, демократлар партиясеннән президентлык постына кандидат итеп сенатор Уилләр (Монтана штатыннан) [illegible]. Ләкин ул үзенең теләге турында хәзергә кадәр берни дә белдерү ясамады. Президент Гардинг заманында Уилләр либерал дигән исем казанды, чөнки ул [illegible] нефть участокларын сату мәсьәләсендәге атаклы аферасын фаш итүгә ярдәм иткән иде. Бу аферада [illegible] югары дәрәҗәле кешеләр дә катнашканнар иде. Матбугатның хәбәр итүенә караганда, Уилләр бакыр промышленносте компаниясе булган „Анаконда“ белән нык элемтәдә тора. Бу компания аша Монтана штатының барлык экономикасын контрольдә тота. Шул ук вакытта Уилләр Американың күренекле профсоюз даирәләре белән дә элемтә тота. Тышкы политика мәсьәләсендә Уиллер да нейтралитетны саклау ягында тора.

Президентлыкка кандидатлары куелу ихтимал дип саналган башка демократлар арасында Хэлл, Фарли, җир эшләре министре Уоллес, генеральный прокурор Джэксон, Филиппин атауларының элекке губернаторы Макнат бар. [illegible]

[illegible] Нью-Йорк прокуроры Дьюи, сенатор Ванденберг, сенатор Тафт, издатель Ганнет бар.

Ганнет (республиканчы), элекке президент Гувер, республиканчы сенатор Бриджес (Нью—Гемпшир штатыннан) һәм башкалар да [illegible] реакционерлар. Республикачылар партиясенең җитәкче даирәләренең реакцион позициясе белән чагыштырганда партиянең рядовой членнарының позициясе башкачарак. „Американың җәмагатьчелек фикере институты“ халыкның төрле катлаулары арасындагы республикачы—сайлаучылар арасында, үткән президент сайлауларында республикачылар партиясе алып барган программага караганда да прогрессиврак программа күтәрергә кирәк дип санамысызмы дигән сорау үткәрде. Соралган кешеләрнең 59 проценты саныйбыз дип җавап бирделәр.

Эшсезләрнең бөтен Америка оешмасы „Эшчеләр альянсы“ өченче партия төзү фикерен күтәрде. Производство профсоюзлары конгрессы, партиясез эшчеләр лигасы һәм башка төрле массовый оешмалар элек Рузвельт политикасына тәнкыйть беләнрәк караган булсалар да, сайлаулар вактында нинди позициядә торачакларын әле һаман белдергәннәре юк.

Президент һәм вице-президент сайлаудан тыш, 5 нче ноябрьдә вәкилләр палатасы сайлау һәм сенат составының өчтән бер өлешен сайлау булачак. Хәзерге сессия башланганда вәкилләр палатасында 261 демократ, 164 республикачы, 2 прогрессив партия члены, 1 фермерлар—эшчеләр партиясе члены, 1 Америка эшчеләр партиясе члены бар иде һәм 6 урын буш иде. Сенатта 69 демократ, 23 республикачы, 2 фермерлар—эшчеләр партиясе члены, 1 прогрессив партия члены һәм 1 бәйсез бар иде.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Кытай частьләре Гуандун провинциясенең көнбатыш өлешендәге Сяодун якынында ике пунктны алдылар.

Гуандун провинциясенең төньяк-көнчыгыш өлешендә Сватоу районында япон гаскәрләренең һөҗүме уңышсыз чыкты.

Хайнань атавында калган кытай гаскәрләре атауның үзәк өлешенә үтеп кергән япон гаскәрләренең тылыннан удар ясауны дәвам иттерәләр.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. 11 нче мартта кытайларның зенит артиллериясе Аньхуэй провинциясенең көньяк өлешендә япон самолетын бәреп төшергән.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә кытай гаскәрләре Уюаньны чолгап алуны дәвам иттерәләр.

Пәнҗаб провинциясендә Англиянең элекке губернаторын үтерү

ЛОНДОН, 14 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә Лондонда Көнчыгыш Һиндстан ассоциациясе җыелышында, Кэкстонхолл бинасында билгесез һинд 4 тапкыр атып, Пәнҗаб провинциясенең элекке губернаторы О'Двайерны үтергән. Һиндстан һәм Бирма эшләре министре Зетлэнд, Бомбей провинциясенең элекке губернаторы Ламингтон һәм күп кенә башка кешеләр яраланганнар. Атучы кулга алынган. Ул үзен инженер Азад дип күрсәткән. Азадның әйтүенчә ул, 1919 нчы елны О'Двайер Пәнҗаб провинциясенең губернаторы булган чагында Амритсарда һиндлеләрне аттырган өчен үч алган.

БЕЛДЕРҮ

Бүген, 16 нчы март кич 6 сәгатьтә, ВКП(б) Өлкә Комитетының Партия Мәгарифе йортында, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ ның VII нче бүлегенә карата татар телендә лекция була. Тема: „Большевикларның Апрель конференциясе“.

Лектор—иптәш Вахитов.

ТӨЗӘТҮ

Газетабызның 15 нче март номерында, 3 нче биттә, „...Ленин исемендәге колхоз председателе иптәш Максимов речениннән“ дигән сүзләрне „Мысль Ленина“ колхозы председателе иптәш Максимов речениннән“ дип төзәтеп укырга кирәк.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ВЫБОРГ

Финляндиянең иң зур шәһәрләреннән берсе булган Выборг Ленинградтан 6—7 сәгать барырлык ераклыкта урнашкан. Бу шәһәрнең борынгы чоры турындагы мәгълүматлар тарихта бик аз сакланган. Выборг бухтасының ерак почмагындагы Бьерке атавының X нчы йөздә үк инде җанлы сәүдә үзәге булганлыгы билгеле. XIII нче йөз азагында бу атауга Швеция бик нык игътибар бирә башлады. Россиягә каршы үзенең басып алу планнарын тормышка ашыру өчен Швеция аны терәк пункт итеп сайлап алды.

Бугазлар белән чолгап алынган атауда 1293 нче елны Швеция короле Биргерның опекуны генерал-фельдмаршал Торкель Кнутсон Выборг дип аталган сарай төзеде. Бу сарай Швециянең көнчыгышта өстенлек итүенең форпосты булырга тиеш иде. Бу сарайның тирә-ягында акрынлап көчле хәрби крепость, ә аннары шәһәр дә төзелде.

Выборгны алу өчен Швеция, Дания, Польша һәм Россия чиксез күп сугышлар алып бардылар. Бөек Новгород та Выборгка каршы үзенең полкларын җибәрде. Иван III нче гаскәрләре дә Выборг өчен сугыштылар. Выборг сигез тапкыр яндырылды. 21 елга сузылган Төньяк сугышыннан соң Выборг Россиягә кушылды.

Тарихчы бу турыда болай ди: Выборгны чолгап алу гадәттән тыш уңайсыз шартларда барды, граф Апраксин командованиесендәге 13 мең кешелек корпус каты суыклар вактында боз даласы аша Кронштадттан Выборгка искиткеч кыен поход үткәрде. Чит илләрнең хәрби күзәтчеләре рус гаскәрләренең гадәттән тыш чыдамлыкларына, үз-үзләрен аямауларына һәм геройлыкларына таңга калдылар. Фин заливының бозы китә башлагач, азыкка зур мохтаҗлык кичергән Апраксин корпусына ярдәмгә Петр I нче җитәкчелегендәге флотилия барды. Патша флотилиясенә күп көннәр буе бозларга каршы көрәшергә туры килде.

Выборг крепостен чолгап алу 12 атнага сузылды. Бер-бер артлы рәхимсез сугышлар барды. 1710 нчы елның июнь урталарында Выборг крепосте алынды, 16 нчы июньдә Петр җитәкчелегендәге рус гаскәрләре шәһәргә керделәр.

Ул замандагы тарихчылардан берәү, рәсми карашны чагылдырып, болай дип язган иде: Выборг Финляндиянең бердән-бер зур крепосте, шведларның иң әһәмиятле стратегик пункты иде. Алар моннан диңгез юлы белән дә, коры юл белән дә Петербургка куркыныч тудырдылар. Выборг Швеция флоты өчен терәк булып, яр буендагы вак атауларга капка булып хезмәт итте.

Выборг алыну белән рус флотына Фин заливының көнчыгыш өлешендә йөрү куркынычсызрак булып әверелде. Шуңа күрә дә ул заманда патша Выборгны „тагын да ныгытырга кирәк“ дигән карарга килде.

Шуннан соңгы вакыйгалар Петрның бу карашы дөрес булганлыкны күрсәттеләр. Уннарча еллар буена Россиягә каршы көрәш өчен Выборгтан файдаланырга маташулар булды.

Империалистлар Выборгны СССР га каршы дошманлык хәрәкәтләре өчен форпостка әйләндерергә тырыштылар. Финляндиянең ак гвардеец, буржуаз-алпавыт җитәкчеләре, хәрби ныгытмалар, хәрби-азык базалары төзү өчен, Выборгны һәм Выборг губернасын чит ил генеральный штабларына, беренче чиратта Англиянең һәм Франциянең генеральный штабларына тапшырдылар. Выборгта асылда Англиянең һәм Франциянең генеральный штаблары хуҗа булдылар. Ак финнәр һәм аларның хуҗалары булган чит ил империалистлары СССР га каршы хәрби интервенцияне тормышка ашыру өчен, Ленинградка һөҗүм итү өчен Выборг губернасын иң әһәмиятле плацдарм дип карадылар.

Выборг районында ак гвардеец маннергеймче шюцкорлар бандаларының сайланма частьләре тупланган иде. Советка каршы шпионнар-диверсантлар оешмасы булган „Карелия академик җәмгыяте“ анда аеруча актив эш алып барды. Башкала итеп Ленинградны һәм Советның Урал тауларына кадәр булган башка күп кенә территорияләрен кертеп, „Бөек Финляндия“ төзү үзенең максаты икәнлекне бу җәмгыять ачыктан-ачык белдерде.

Выборг патша Россиясенә каршы фин пролетариатының революцион көрәш үзәге булды. Финляндиядә революцион властьның соңгы көннәре трагедиясе Выборгта һәм аның районнарында булды. Революцион фин пролетариатына каршы көрәшү өчен, 1918 нче елның апрель башында Ганге портына 30 хәрби караб белән берлектә 10 океан пароходында чит ил интервентлары килде.

14 нче апрельдә урамнарда барган каты сугышлардан соң ак гвардеецлар Гельсингфорсны, аннан соң Таммерфорсны алдылар. Интервентлар үзләренең көчләрен Выборгка каршы юнәлдерделәр. Аларга ярдәмгә Ловизега чит ил гаскәрләренең тагын бер десанты төшерелде. Котка Ярвила—Лахти районында фин кызыл гвардеецларының 30 мең кешелек армиясен ак гвардеецлар һәм интервентлар чолгап алдылар. Кызыл гаскәрләрнең командованиесе дошманның боҗрасыннан көч белән бәреп үтәргә карар бирде. Ләкин аның 5 мең кешелек көньяк колоннасы гына дошман боҗрасыннан үтеп чыгып, Советлар Россиясенә чигенә алды. Шуннан берничә көн элек, 29 нчы апрельдә, фин ак гвардеецлары һәм интервентлар Выборгны алдылар. Маннергейм бандаларының коралсыз эшчеләрне һәм крестьяннарне ерткычларча, рәхимсез җәзалаулары башланды. Меңнәрчә кызыл сугышчылар атып үтерелделәр.

Фин заливы янында, Саймин каналы тамагында урнашкан Выборгның уңайлы географик хәле аңа Финляндиянең иң әһәмиятле сәүдә портларыннан берсе булып әверелергә мөмкинлек бирде.

Шулай ук Выборг—агач эшкәртү промышленностеның һәм урман экспортының иң зур үзәкләреннән берсе. Шәһәрнең тирә-ягында агач эшкәртә торган күп кенә предприятиеләр урнашкан. Ул—шулай ук әһәмиятле авыл хуҗалыгы һәм сөт хуҗалыгы үзәге дә. Халкының саны ягыннан Хельсинки, Турку һәм Тампере шәһәрләреннән кала Выборг дүртенче урында торды.

„Труд“.

Б. Баратов.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 16 нчы мартта
РЕВИЗОР
Талоннар белән кертелми.
Иртәгә кич һәм 18 ндә көндез
ПАВЕЛ ГРЕКОВ
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында.
Бүген, 16 нчы мартта
ИРЕК
Талон 38.
Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
19 нчы мартта Зур театр бинасында
ФАУСТ
Талоннар белән кертелми.
Коллектив рәвештә килү өчен 20—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген, 16 нчы мартта, данлыклы
ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ
300 хайван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛОның
соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.
Уен кич 8 дә башлана.
18 нче мартта зур программада
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

Киров районындагы
КУЛЬТУРА САРАЕ
Бүген, 16 нчы мартта
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар белән кертелми.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
17 нче мартта
Булак арты „республикасы“
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы, яңа фильм ТАШЛАНДЫК
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ПРЕМЬЕРА ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ПРИДАНСЫЗ КЫЗ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	ПАТРИОТ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	ХӘЗИНӘЛӘР АТАВЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ЯШӘРГӘ

„Татхудожник“ кооператив җәмгыяте правлениесенең югалган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга.
486—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 43 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1030.